КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 26 сентябрь г.Казань № 877

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 14 февраль, 97 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 14 февраль, 97 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 11 февраль, 105 нче; 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче; 2015 ел, 19 март, 165 нче; 2017 ел, 26 май, 307 нче; 2018 ел, 12 декабрь, 1117 нче; 2019 ел, 7 март, 163 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 нче пунктка татар текстында «Татарстан Республикасы акчасы исәбеннән сатып алынган юлламаларны» сүзләреннән соң «(алга таба – юлламалар)» сүзләрен өстәргә;

1.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Ташламалы шартларда юлламалар белән пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, башка нигезләр буенча пенсия алучы яки «Иминият пенсияләре

турында» Федераль законның 8 статьясындагы беренче өлеш нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирүче яшькә җиткәч эш (хезмәт) өчен гомерлек акчалата керем алучы пенсионерлар, Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, гаиләсенең җан башына исәпләнгән уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән пенсионерның яшәү минимумы күләменең 400 процентыннан артмаган һәм мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законына теркәлгән кушымта белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган 60 һәм 55 яшькә җиткән гражданнар (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Авыруларны медицина күрсәткечләре нигезендә сайлап алу һәм шифаханә-курорт дәвалавына җибәрү тәртибе турында» 2004 ел, 22 ноябрь, 256 нчы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Амбулатория шартларында медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында кулланыла торган медицина документларының унификацияләнгән формаларын һәм аларны тутыру тәртипләрен раслау турында» 2014 ел, 15 декабрь, 834 нче «н» боерыгы белән расланган 070/у формасы буенча бирелә торган белешмә кәгазе (алга таба – 070/у формасы буенча шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен белешмә кәгазе) белән расланган шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗ булу турындагы медицина күрсәткечләре булган шартларда тәэмин ителә.

Торак урыннары мәйданын исәпләгәндә Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты белән күздә тотылган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруның авыр төре белән интегүче, аның белән законнар нигезендә бергә яшәү мөмкин булмаган гражданның гаилә әгъзасы били торган торак урыны мәйданы (шул исәптән фатирдагы аерым изоляцияләнгән торак урыны мәйданы) исәпкә алынмый.

Ялгыз яшәүче гражданның мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсен билгеләгәндә «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законына теркәлгән кушымтаның «а» пунктчасы нигезендә 40 квадрат метр урынына 80 квадрат метр кулланыла.»;

1.3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Граждан гаиләсенең җан башына уртача кереме һәм ялгыз яшәүче граждан кереме «Гаиләнең һәм ялгыз яшәүче гражданның керемнәрен исәпкә алу һәм аларны аз керемлеләр дип тану һәм аларга дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен бер кешегә уртача керемне исәпләү тәртибе турында» 2003 ел, 5 апрель, ФЗ-44 нче Федераль закон (алга таба – 2003 ел, 5 апрель, ФЗ-44 нче Федераль закон) белән билгеләнгән тәртиптә исәпләнә.

Граждан гаиләсенең җан башына уртача керемен исәпләү өчен гаилә составы 2003 ел, 5 апрель, ФЗ-44 нче Федераль законның 13 һәм 14 статьялары нигезендә билгеләнә.

Гражданның мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсен билгеләгәндә гаилә составына керемнәре граждан гаиләсенең җан башына уртача керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган затлар кертелә.»;

1.4 нче пунктта «пенсионерның» сүзен «гражданның» сүзенә алыштырырга;

2 бүлекнең исемендә «Шифаханә-курорт дәвалавына» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында (алга таба – КМБДР) хокуклары теркәлмәгән күчемсез мөлкәт объектларына хокукны билгеләүче документлар күчермәләре;

әгәр дә бу Нигезләмәнең 3.1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнарның гаилә составына Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты белән күздә тотылган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруның авыр төре белән интегүче, аның белән законнар нигезендә бергә яшәү мөмкин булмаган затлар керсә, Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты белән күздә тотылган исемлектә күрсәтелгән, аның белән законнар нигезендә бергә яшәү мөмкин булмаган хроник авыруның авыр формасы булу турында белешмә.»;

2.2 нче пунктның 2.2.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.1. Гражданны юллама алуга исәпкә кую турында карар кабул итү өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматларны ведомствоара сораулар нигезендә, шул исәптән, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә ала:

вәкаләтле оешмалардан «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү турында мәгълүматлар;

вәкаләтле оешмалардан гариза бирүченең гаилә составы турында мәгълүматлар;

Россия Федерациясе Пенсия фондында булган керемнәр турында мәгълүматлар;

күчемсез мөлкәт булу турында мәгълүматлар;

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төрләре булу турында мәгълүматлар;

торак урынын билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип тану турында мәгълүматлар;

индивидуаль шәхси исәпнең иминият номеры (СНИЛС) турында мәгълүматлар.

Шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре булу турында мәгълүмат алмашу мәсьәләсе буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кертелгәннән соң, шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәтмәләренең булуы турында мәгълүматлар ала.

Граждан үз теләге белән бу пунктның икенче – сигезенче абзацларында күрсәтелгән мәгълүматлары булган документларны гариза белән бергә территориаль социаль яклау органына тапшырырга хокуклы.»;

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Гражданны юллама алуга исәпкә куюдан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

2.1 нче пунктта күрсәтелгән документларны тапшырмау яки аларның тулы булмаган пакетын тапшыру;

гамәлдә булу вакыты чыккан документларны тапшыру;

граждан (ялгыз яшәүче граждан) гаиләсенең җан башына уртача кереме күләме Татарстан Республикасында билгеләнгән пенсионерның яшәү минимумы күләменнән 400 процентка артып китү;

бу Нигезләмәнең 1.2 нче пунктындагы икенче һәм өченче абзацлары һәм 1.3 нче пунктының өченче абзацлары нигезләмәләренә таянып, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законына теркәлгән кушымта белән билгеләнгән гражданның мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсе гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән артып киткән булу;

граждан Татарстан Республикасыннан читкә чыгу;

гражданның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә шифаханә-курорт дәвалавы хокукына ия булган категориягә каравы.»;

3 бүлекнең исемендә «Шифаханә-курорт дәвалавына» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 нче пунктта:

икенче абзацта «юлламалар» сүзләреннән соң «(юлламалар керү турында мәгълүмат)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Территориаль социаль яклау органы гражданга бу Тәртиптнең 3.5 нче пунктындагы дүртенче – сигезенче абзацлары белән күздә тотылган нигезләр буенча юллама бирүдән баш тарту турында карар кабул иткәндә граждан юллама алу өчен исәптән төшерелә.»;

3.3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Юллама алучыга аның гамәлдә булу вакыты башланганга кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча бирелә.

Юлламаны алганнан соң граждан җитди сәбәпләр аркасында шифаханә-курорт дәвалавыннан файдалана алмаган очракта, ул юлламаны территориаль социаль яклау органына кире кайтарырга һәм шифаханә-курорт дәвалавын үтүдән баш тарту өчен нигез булып торган объектив сәбәпләрне раслаучы документлар белән юлламадан баш тартуның җитди сәбәпләре булу турындагы мәгълүматны юлламаның гамәлдә булу вакыты чыкканга кадәр алты эш көненнән дә соңга калмыйча язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

Баш тарту факты территориаль социаль яклау органы тарафыннан язмача теркәлә. Кире кайтарылган юллама баш тартылган көннән бер эш көне эчендә республиканың тиешле муниципаль районында яки шәһәр округында исәпкә кую датасы буенча авыруның тиешле профиле булган икенче кешегә бирелә (070/у номерлы форма буенча шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен белешмә нигезендә).

Граждан бу пунктның икенче абзацы белән күздә тотылган бурычын җитди сәбәпләр аркасында үтәмәгәндә граждан юллама алуга үз хокукын тормышка ашырган дип санала һәм юллама алу өчен исәптән төшерелә.»;

3.5 нче пунктта:

икенче абзацта «бу Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки аларның тулы булмаган пакетын» сүзләреннән соң «(гамәлдә булу вакыты чыккан очракта)» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацка «бу Тәртипнең 1.2 нче пунктындагы икенче һәм өченче абзацлары һәм 1.3 нче пунктының өченче абзацы нигезләмәләренә таянып билгеләнгән» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гражданинның тәкъдим ителгән юлламадан ике тапкыр рәттән җитди сәбәпләрсез баш тартуы. Җитди сәбәпләр гражданның тәкъдим ителгән юлламадан баш тарту өчен объектив сәбәп булган вакыйгаларны раслый торган документлар белән раслана.»;

Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
пенсионерларын шифаханә-
курорт дәвалавы белән
тәэмин итү тәртибенә
1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 26 сентябрь, 877 нче
карары редакциясендә)

Юллама өчен граждан үзе түли торган акча
күләме

| Төр-кем | Граждан гаиләсенең җан башына уртача кеременең (ялгыз яшәүче граждан кеременең) Татарстан Респиубликасында билгеләнгән пенсионерның яшәү минимумы күләменә карата күләме процентта | Юллама өчен граждан үзе түли торган акча күләме, юллама кыйммәтеннән процент |
|---|---|---|
| I | 200 гә кадәр (200 не кертеп) | 5 |
| II | 200 дән артык 250 гә кадәр (250 не кертеп | 10 |
| III | 250 дән артык 300 гә кадәр (300 не кертеп) | 15 |
| IV | 300 дән артык 350 гә кадәр (350 не кертеп) | 20 |
| V | 350 дән артык 400 гә кадәр (400 не кертеп) | 25 |

Татарстан Республикасы
пенсионерларын шифаханә-
курорт дәвалавы белән
тәэмин итү тәртибенә
2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 26 сентябрь, 877 нче
карары редакциясендә)

Форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы __________________ муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) Социаль яклау идарәсе (бүлеге) җитәкчесенә

____________________________________ булган
(гариза бирүче категориясе)

__________________________________________,
(Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

Паспорт сериясе ________ № ________________
Кайчан, кем тарафыннан бирелгән ___________
__________________________________________
СНИЛС* __________________________________
Яшәү урыны буенча теркәлү адресы _________
__________________________________________
Фактта яшәү адресы ________________________
__________________________________________

Телефоннары:
өй: ______________________________________
мобиль: __________________________________
e-mail:____________________________________

Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына
юллама белән тәэмин итүгә
ГАРИЗА

Сездән ____________________________________________________________
(Ф.И.Ат.ис. тулысынча (соңгысы – булганда))

* Тутыру өчен мәҗбүри түгел.

________ елның _____________ендәге (ындагы) 070/у номерлы форма буенча ________________________________________ шифаханә-курорт дәвалавына юллама
(авыру коды)
алу өчен тапшырылган белешмә нигезендә ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итүегезне үтенәм.

1. Гаилә составы турында мәгълүматлар*:

| Т\с | Ф.И.Ат.ис. | Туганлык мөнәсәбәтләре |
|---|---|---|
| 1. | | |
| 2. | | |
| 3. | | |

2. Гариза бирүче һәм аның гаилә әгъзалары милкендә булган мөлкәт турында мәгълүматлар*:

| Т\с | Ф.И.Ат.ис. | Мөлкәт төре | Милек төре |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |
| 3. | | | |
| 4. | | | |
| 5. | | | |
| 6. | | | |

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 ел, 27 июль, ФЗ-152 нче Федераль закон нигезендә бу гаризада күрсәтелгән шәхси мәгълүматларны әлеге мәгълүматларны мәгълүмати алмашу системасында эшкәртүгә, шул исәптән җыю, аныклау, куллану, өченче затларга тапшыруга үземнең ризалыгымны бирәм.

Тапшырылган мәгълүматларның һәм документларның дөреслеген раслыйм.

Мәгълүмат, шул исәптән ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итү турында йә ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итүдән баш тарту турында мәгълүмат алырга риза. Түбәндәге юллар белән хәбәр итүгә риза:

почта адресы буенча язма рәвештә: ______________________________________;

телефонга СМС-хәбәр итеп: _____________________________________________;

электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә: _______________
_____________________________________________________________________________;

________________________

* Тутыру өчен мәҗбүри түгел

«Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында шәхси кабинет аша: ________________________________________________________________.

Мине шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итүгә, шулай ук хәбәр итүгә кагылышлы нинди дә булса үзгәрешләр (адрес, телефон һ.б.) булган очракта, бу турыда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы __________________ муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) Социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) хәбәр итәргә кирәклеге хакында мин беләм.

20____ елның «__» __________ _______________ ____________________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

Гаризаны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы __________________ муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) Социаль яклау идарәсе (бүлеге) белгече кабул итте.

Гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документтагы мәгълүматлар тикшерелде.

Гариза аңа теркәлгән документлар белән ________ нөсхәдә кабул ителде һәм _______ елның ____________ендә (ында) ________ номеры белән теркәлде.

20__ елның «__» ___________ ____________ _________________________________
(имзасы) (белгечнең Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

____________________________ кисеп алу линиясе ____________________________

Гаризаны алу кәгазь

________ елның _____________ендәге (ындагы) 070/у номерлы форма буенча _____ _______________________________ шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен
(авыру коды)

тапшырылган белешмә нигезендә __________________________________________
(Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

шифаханә-курорт дәвалавына юллама бирү турындагы гаризаны ________________ __________________________________________ Татарстан Республикасы Хезмәт,
(Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы ___________________ муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) Социаль яклау идарәсе (бүлеге) белгече кабул итте.

20__ елның «__» ___________ ____________ _________________________________
(имзасы) (белгечнең Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

_____________________________________